Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәренә якынча җаваплар (мәктәп туры, 2017-2018 уку елы). 7 нче сыйныф

Максималь балл – 38.

I. Теоретик биремнәр. (8 балл)

1. Тезмә формада язылган нинди халык авыз иҗаты жанрларын билгели аласыз? Һәркайсына мисаллар китерегез. (5 балл)

Җыр, бәет, дастан.

2. Түбәндә аталган жанрларның кайсылары халык авыз иҗатына карый. (3 балл)

А) **дастан**
Б) **миф**
В) комедия
Г) **мәзәк**
Д) баллада

II. Әдәби әсәргә кагылышлы биремнәр. (15 балл)

1. “Идегәй” дастанында Идегәй һәм Норадын образларына, аларның эш-гамәлләренә чагыштырма характеристика бирегез. (10 балл)

2. “Идегәй” дастанында җиткерелгән төп идеяне ачыклап языгыз, геройлар, аларның эш-гамәлләре аша укучыга нинди фикер әйтелә? (5 балл)

Көнчелек, мәкер, хыянәт кебек куркыныч сыйфатлар кешеләр, халык язмышына тискәре йогынты ясый, дәүләтне тарката, һәр халык, иң беренче чиратта, үз язымышы, үз бәхете өчен үзе җаваплы h.б.

II. Иҗади эш. (15 балл)

Соңгы елларда киң кулланылышта булган *компьютер, ноутбук, телефон, планшет, телевизор* турында 5 табышмак уйлап чыгарып языгыз.